| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.11.2021 г.Казань № 805

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 11 ноябрендәге 8091 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елның 11 маенда «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесендә кылынган аеруча катлаулы җинаять нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 11 маендагы 298 номерлы боерыгы белән расланган 2021 елның 11 маенда «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесендә кылынган аеруча катлаулы җинаять нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2021 елның 11 маенда «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесендә кылынган аеруча катлаулы җинаять нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 11 маендагы 298 номерлы боерыгы белән расланган 2021 елның 11 маенда «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесендә кылынган аеруча катлаулы җинаять нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән затлар исәбендәге, сәламәтлегенә зыян килгән гражданинга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү өчен:

сәламәтлегенә зыян килгән гражданинны аеруча катлаулы җинаять факты буенча җинаять эшендә зыян күрүче дип тану турында;

ундүрт яшенә җитмәгән, сәламәтлегенә зыян салынган балигълык яшенә җитмәгән баланың тууын (уллыкка алынуын) дәүләт теркәвенә алу турында;

сәламәтлегенә зыян салынган гражданинга карата опека (попечительлек) билгеләнүе турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында, ата-ана хокукында чикләүне гамәлдән чыгару турында белешмәләр, гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда ундүрт яшенә җитмәгән, сәламәтлегенә зыян китерелгән балигълык яшенә җитмәгән гражданинны йолып алу турында белешмәләр;

сәламәтлегенә зыян салынган, ундүрт яшенә җитмәгән балигълык булмаган граждаинның, ата-анасының яки мондый баланың башка законлы вәкиленең хокукка сәләтен чикләү яки хокукка сәләтсез дип танылуы турында;

Россия Федерациясе чикләрендә Россия Федерациясе гражданинының яшәгән яки торган урыны буенча теркәлгән яки теркәлмәгән булуы турында;

2021 елның 11 маенда Казан шәһәренең «175 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә аеруча авыр җинаять нәтиҗәсендә сәламәтлеккә китерелгән зыянның сәламәтлеккә булган зыяны турында, сәламәтлеккә китерелгән зыянның авырлык дәрәҗәсен күрсәтеп.

Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча социаль яклау органына әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларны тапшырырга хокуклы.»;

17 пунктта «алты» сүзен «12» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның 2 нче таблицасындагы 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

Министр вазыйфаларын
башкаручы Н.В.Бутаева